ГЛАВА
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04.08.2026 с.Старое Дрожжаное № 33

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Марс авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлауларны билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2021 елның 27 маендагы 9/3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2026 елның 31 июлендәге 01-09-18212 номерлы мөрәҗәгате белән бәйле рәвештә, КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Марс авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.

2. Гавами тыңлауларны оештыручы - коллегиаль киңәшмә орган составын расларга:

1) Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе Р.И. Мөхәммәтҗанов;

2) Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары Р.Р. Баһаутдинов;

3) Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы Рәисе Н.П. Патрина;

4) Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының Шәһәр төзелеше һәм архитектура бүлеге башлыгы И.М. Хусаинов;

5) Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының Төзелеш һәм ТКХ бүлеге башлыгы Ю.И. Шуркин;

6) Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Марс авыл җирлеге башлыгы Р.М. Җамалетдинов;

7) «Татарстан Республикасы пространство белешмәләре фонды» ДБУ вәкиле (килешү буенча).

3. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетына гавами тыңлауларны оештыручыга җирле үзидарә, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы кануннар нигезендә гавами тыңлауларны оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.

4. Кызыксынучы затларга гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турындагы бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр - бер айдан да артык булмаган вакыт эчендә һәм 2026 елның 31 августыннан дә соңга калмыйча тәмамланырга тиеш дип билгеләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында (www.droganoye.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе Р.И. Мөхәммәтҗановка йөкләргә.

Чүпрәле муниципаль районы
Башлыгы М.Р. Гафаров